# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Загорье торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**11 окбябрь 2031 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле узидарә оештырунын гомуми принциплары турында» Федераль законнын 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл жирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Загорье торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гаиләләре махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Загорье торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә узара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

1) Загорье бистәсендә урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы;

2) Загорье торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

3) Загорье бистәсендә традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы: Г.И. Аскарова